**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2025 елның 7 октябрендәге 3380 номерлы карары**

**Казан шәһәре Башкарма комитетының 2023 елның 26 апрелендәге 1189 номерлы «Муниципаль милектә булган җир кишәрлеген, сатулар үткәрмичә, милеккә, арендага, даими (вакыты чикләнмәгән) файдалануга, бушлай файдалануга бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында»гы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Россия Федерациясе Җир кодексының 39.16 статьясына 2025 елның 31 июлендәге 353-ФЗ номерлы «“Гражданнар тарафыннан үз ихтыяҗлары өчен бакчачылык һәм яшелчәчелек алып бару һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында”гы федераль законга һәм Россия Федерациясенең кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү турында»гы федераль законга үзгәрешләр кертелүгә бәйле рәвештә **карар бирәм:**

1. Казан шәһәре Башкарма комитетының 2023 елның 26 апрелендәге 1189 номерлы карары (аңа Казан шәһәре Башкарма комитетының 2024 елның 1 апрелендәге 1242 номерлы, 2024 елның 14 маендагы 2005 номерлы, 2024 елның 30 сентябрендәге 4087 номерлы, 2025 елның 21 гыйнварындагы 71 номерлы, 2025 елның 30 апрелендәге 1330 номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) белән расланган Муниципаль милектә булган җир кишәрлеген, сатулар үткәрмичә, милеккә, арендага, даими (вакыты чикләнмәгән) файдалануга, бушлай файдалануга бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентының 2.8.4.1 пунктчасына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 3 пунктчаны түбәндәге редакциядә бирергә:

«3) җир кишәрлеге бирү турындагы гариза белән коммерциягә нигезләнмәгән бакчачылык яки яшелчәчелек ширкәте әгъзасы (әгәр мондый

җир кишәрлеге бакчачылык яисә яшелчәчелек белән шөгыльләнү өчен каралган булса) яисә коммерциягә нигезләнмәгән бакчачылык яки яшелчәчелек ширкәтендә катнашу (әгъзалык) хокукына ия булмаган, федераль законнар, Россия Федерациясе субъектлары законнары нигезендә җир кишәрлеген беренче чиратта яисә чираттан тыш сатып алуга яисә Җир Кодексының 39.18 статьясы нигезендә җир кишәрлеге сатып алуга хокукы булган гражданның (әгәр мондый җир кишәрлеге бакчачылык кишәрлеге булса), шулай ук гражданнарның үз ихтыяҗлары өчен бакчачылык яисә яшелчәчелек белән шөгыльләнү территориясе чикләрендә урнашкан җир кишәрлекләре хуҗалары (әгәр җир кишәрлеге гомуми билгеләнештәге җир кишәрлеге булса) мөрәҗәгать иткән очраклардан тыш, мондый гаризада күрсәтелгән җир кишәрлеге коммерциягә нигезләнмәгән бакчачылык яки яшелчәчелек ширкәтенә бирелгән җир кишәрлеген бүлү нәтиҗәсендә ясалган булу;

1.2. 13 пунктчада «хуҗалык» сүзеннән соң «торак пунктлары чикләрендә» дигән сүзләр өстәргә;

1.3. 17 пунктчада «чик» сүзен төшереп калдырырга.

2. Әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары Р.Р.Шәфигуллинга йөкләргә.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**